| | |
|---|---|
| СОВЕТ НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

21.09.2018 с. Старое Русское Маматкозино 41-200

Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы, «Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» Яңа Рус Мәмәтхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 14 маендагы 20-ТРЗ номерлы карары нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчалар юлламасы белән килешәсезме:

- Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең торак пунктларында җирле әһәмияттәге юлларга вак таш түшәү

ӘЙЕ ЮК

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан

муниципаль районының рәсми сайтында, Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгы В. В. Никитушкин